ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2023 г. Заинск № 1085

**2023 елда иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын үткәрү турында**

Яңа ел чорында бәйрәм атмосферасы тудыру, Зәй муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре территорияләренең архитектур күренешен яхшырту һәм территорияләрне төзекләндерү максатыннан, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2023 елда Зәй муниципаль районының барлык милек формасындагы оешмалары һәм учреждениеләре арасында биналарның, якынтирә территорияләрнең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын үткәрергә.
2. 2023 елда Зәй муниципаль районының барлык милек формасындагы оешмалары һәм учреждениеләре арасында биналарның, якынтирә территорияләрнең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын үткәрү турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Конкурсны үткәрү буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).
4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.Ю.Ревина
3-41-22

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.12 2023 ел
1085 номерлы карарына
1 кушымта

**2023 елда Зәй муниципаль районының барлык милек формасындагы оешмалары һәм учреждениеләре арасында биналарның, якын-тирә территорияләрнең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын уздыру турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге 2023 елда Зәй муниципаль районының барлык милек формасындагы оешмалары һәм учреждениеләре арасында биналарның, якын-тирә территорияләрнең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын уздыру турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибен һәм шартларын билгели.
1.2. Конкурсның төп максатлары:
1) Яңа ел бәйрәмнәрен уздыру чорында бәйрәм атмосферасы тудыру;
2) Зәй муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре территорияләренең архитектур күренешен яхшырту һәм төзекләндерү.
1.3. Бәйгене Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты оештыра.

## II. Конкурс үткәрүнең тәртибе һәм шартлары

2.1. Конкурс 16 декабрьдән 20 декабрьгә кадәр уздырыла.
2.2. Конкурста барлык милек рәвешендәге предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр (алга таба - конкурста катнашучылар) катнаша.
2.3. Конкурс түбәндәге категорияләр арасында уздырыла:
- сәнәгать предприятиеләре;
- кулланучылар базары (сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре һәм башкалар);
- бюджет оешмалары һәм учреждениеләре;
- белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре;
- торак милекчеләре ширкәтләре һәм идарәче компанияләр;
- авыл җирлекләре.

2.4. Конкурс барышын һәм йомгаклауны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты оештыра.

## III. Җиңүчеләрне билгеләү критерийлары

3.1. Конкурста катнашучылар арасында җиңүчеләрне билгеләү критерийлары түбәндәгеләр:
1) фасадны һәм керү өлешен бизәү: хәрефләр яисә яктылык тартмалары рәвешендә Яңа ел котлавы булу; яктыртылган фигуралар һәм (яки) “яктылык янгыры”, шулай ук чыршы ботакларыннан ясалган гирляндалар белән бизәү;
2) чын һәм ясалма чыршылар урнаштыру; территориядә урнашкан агачларны яктырткычлар, “яктылык яңгыры” яки уенчыклар белән бизәү;
3) янәшәдәге территорияне бизәү: кар һәм (яки) боз фигураларын, төрле технологияләр белән башкарылган күләмле скульптураларны куллану;
4) витражлар һәм витриналар, тәрәзәләр, балконнарны бизәү: Яңа ел белән котлаулар булу; яктылык гирляндалары, яктылык шнурлары, шулай ук башка декоратив яктырткычлар белән бизәү;
5) декоратив шарлар, мишуралар, яктылык фигуралары, Кыш Бабай һәм Кар кызы фигуралары, кар бабай сыны, шулай ук көнчыгыш календаре буенча хайваннар сыннары һәм башка сурәтләр куллану.
3.2. Конкурста катнашучыларның гомуми керү урыны булган очракта, керү төркемен, фасадны һәм (яисә) якын территорияне бизәү гомуми килештерелгән проект буенча башкарыла.

## IV. Конкурска нәтиҗә ясау

4.1. Конкурска йомгак конкурс комиссиясе тарафыннан тантаналы шартларда ясала.
4.2. Конкурста катнашучылар ун баллы шкала буенча түбәндәге тәртиптә бәяләнә:
1) әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән һәр критерий буенча конкурста катнашучыга бердән алып ун баллга кадәр бәя куела;
2) баллар саны барлык критерийлар буенча бергә кушыла;
3) иң күп балл алган катнашучылар конкурста җиңүче була.
4.3. Конкурс йомгаклары буенча түбәндәге призлы урыннар билгеләнә:
1 урын – һәр категориядә берәр.
2 урын – һәр категориядә икешәр.
3 урын – һәр категориядә икешәр.
Карар конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш бирүе рәвешендә, күпчелекнең тавышы белән, беркетмә рәсмиләштерелеп, кабул ителә.
4.4. Призлы урыннар алучылар дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнә.
4.5. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты өстәмә номинацияләр һәм махсус призлар кертү хокукына ия.

## V. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

5.1. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата премияләр тантаналы шартларда тапшырылачак.

Конкурста катнашучылар түбәндәге күләмдә акчалата премияләр белән бүләкләнә:

1 урын өчен - 10 мең сум;

2 урын өчен - 7 мең сум;

3 урын өчен - 5 мең сум.

Бүләкләү фонды 216 мең сум тәшкил итә.

5.2. Конкурсны финанслау Зәй муниципаль районы бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла.

Приз фонды конкурста җиңүчеләрнең барысы арасында да күрсәтелгән күләмдә бүленә, рамкалар сатып алуга һәм дипломнар әзерләүгә 12 000 сум каралган.

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Е.А.Васильева**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.12 2023 ел
1085 номерлы карарына
2 кушымта

**2023 елда Зәй муниципаль районының барлык милек формасындагы оешмалары һәм учреждениеләре арасында биналарның, якын-тирә территорияләрнең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә «Кышкы әкият» конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Галеев Э.Э. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе – конкурс комиссиясе рәисе; |
| Ревина С.Ю. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы – конкурс комиссиясе рәисе урынбасары; |
| Исламова Р.Р. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы – конкурс комиссиясе секретаре. |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Халикова И.П. | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Хабибуллин М.М. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы; |
| Никифорова Г.Х. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы |
| Исаков А.К. | «Татмедиа» АҖнең «Заинск-информ» филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Павлова Н.Г. | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Сәфәргалиев Э.Р. | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Валиуллина А.Х. | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Уразайкин П.С. | Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Чернова Т.Ю. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенең әйдәп баручы белгече; |
| Аладышкин Р.С. | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Шиапов Ф.А. | рәссам, шәхси эшмәкәр (килешү буенча). |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Е.А.Васильева**